Республика Татарстан
ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423950, п.г.т.Уруссу ул.Пушкина, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

Татарстан Республикасы
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
423950, Урыссу ш.т.б. Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

“ 14 ” 07 2021г. № 63

Татарстан Республикасы
Ютазы муниипаль районы
генераль планы проекты турында
фикер алышу буенча гавами
тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Уставы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Әбсәләм авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча фикер алышу буенча халык тыңлауларын 2021 елның 31 маена 10.00 сәгатькә Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы, Пушкин ур., 38 йорт, район Советының утырышлар залы.

2. Гавами тыңлауларны оештырган һәм уздырган өчен җаваплы итеп Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген билгеләргә.

3. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру буенча законнар, муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәүне;

- кызыксынучы затларга гавами тыңлауларның датасы, вакыты һәм уздыру урыны турында мәгълүмат җиткерүне;

- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмәне үз вакытында әзерләүне һәм халыкка җиткерүне.

4. Тикшерелә торган сорау буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар 2021 елның 31 апреленнән 31 маена кадәр түбәндәге адрес буенча кертелергә мөмкин: Урыссу штп, Пушкин урамы, 38 йорт, 117 бүлмә (эш көннәрендә 9:00 сәгатьтән 15:00 сәгатькә кадәр, тел. 2-73-07).

5. Кушымта нигезендә, кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Ютазы муниципаль районы сайтында http://jutaza.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Ютазы муниципаль
районы башлыгы А.Ә. Шәфигуллин